**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3186**
**07.05.2021**

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеге» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 7 маендагы
3186 номерлы карарына
кушымта

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – регламент) төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (алга таба – АШТҺТҮИ).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

АШТҺТҮИнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 248А кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр.

төшке аш вакыты: 12:00 дән 13:00 сәгатькә кадәр.

ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

АШТҺТҮИнең белешмә телефоннары: 30-55-08, 30-58-12, 30-58-14.

Башкарма комитет бинасына керү шәхесне раслаучы документ буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: https://nabchelny.ru.

АШТҺТҮИнең электрон почта адресы: gradoctroitel@mail.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат түбәндәге юл белән алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә.

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatar.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https://www.gosuslugi.ru);

5) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдаланып;

6) Башкарма комитетта (АШТhТҮИ):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта аша электрон формада.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 03.01.2005, №1 (1 өлеш), ст.16);

2) Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, №44, ст.4147);

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.10.2003, №40, ст.3822);

4) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, №31, ст. 4179);

5) «Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында» 1995 елның 17 ноябрендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 169-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.11.1995, №47, ст. 4473);

6) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.11.1995, №48, ст. 4563);

7) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү өчен кирәкле белдерү кәгазе формаларын раслау турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр номерлы Боерыгы (алга таба – РФ Төзелеш министрлыгы Боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы https://pravo.gov.ru, 28.09.2018);

8) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы) (Челнинские известия, №235-237, 10.12.2005; №249-250, 30.12.2005);

9) Шәһәр Советының 2007 елның 25 октябрендәге 26/4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре;

10) Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары (алга таба – муниципаль хезмәтләр исемлеге);

11) Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

12) Башкарма комитетның 2012 елның 24 маендагы 372 номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе турында нигезләмә (алга таба – АШТhТҮИ турында нигезләмә);

13) Башкарма комитетның 2020 елның 25 февралендәге 101-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

1) Индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү тәмамлану турында белдерү кәгазе (алга таба – төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе) – муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос (1 нче кушымта);

2) техник хата – Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә

нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

3) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны (алга таба – КФҮнең ерактагы эш урыны) – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Яр Чаллы шәһәрендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең (алга таба – КФҮ) территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен хокукый нигезләр |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы;<br>муниципаль хезмәтләр исемлеге |
| 2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме | Башкарма комитет исеменнән АШТһТҮИ | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы;<br>шәһәр Уставының 41 статьясы;<br>АШТһТҮИ турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү кирәк булган Башкарма комитетның структур бүлекчәләре исемлеге | 1) АШТһТҮИ;<br>2) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) | Эш регламентының 3 бүлеге |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазе (2 нче кушымта) яисә төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәве турында белдерү кәгазе (3 нче кушымта).<br>Белдерү кәгазьләренең формалары РФ Төзелеш министрлыгы Прказы белән расланган | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе теркәлгән вакыттан башлап җиде эш көне эчендә | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясының 19 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) РФ Төзелеш министрлыгы Боерыгы белән расланган форма буенча төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе (1 нче кушымта);<br>2) гариза бирүченең яисә гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ;<br>3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән аның вәкиле эш итсә);<br>4) гариза бирүче булып чит илнең юридик заты торган очракта, юридик затны чит ил дәүләт законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның рус телендә расланган тәрҗемәсе;<br>5) индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының техник планы;<br>6) төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрлары турында мәгълүматлар;<br>7) хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру өчен дәүләт пошлинасы түләү турында мәгълүматлар;<br>8) индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты төзелгән яки реконструкцияләнгән җир участогы гомуми өлешле милек хокукында яки арендатор ягында күп санлы затларның аренда хокукында ике һәм аннан күбрәк гражданга караган очракта, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектына яки бакча йортына гомуми өлешле милек хокукында аларның өлешләрен билгеләү турында җир участогының хокук ияләре арасында төзелгән килешү | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясының 16 өлеше;<br>РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 статьясындагы 3 өлешенең 2, 3 пунктлары<br>РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49, 182 статьялары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш булу сәбәпле, гариза бирүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | 1) җир участогына хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, җәмәгать сервитуты билгеләү турында карар;<br>2) рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары һәм җир участогының чикләүләре турында мәгълүмат;<br>3) индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының күрсәтелгән тышкы күренеше тасвирламасының тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының шәһәр төзелеше регламенты белән федераль яки региональ әһәмияткә ия тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата билгеләнгән архитектура чишелешләренә туры килүе яки туры килмәве турында белдерү кәгазе. | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясының 3.2 өлеше |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазендә 1 нче кушымтада күрсәтелгән мәгълүматлар яки регламентның 2.6 пунктында каралган документлар булмау;<br>2) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе (аның нигезендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү гамәлгә ашырылган) кергән көннән башлап 10 ел үткәннән соң кергән яисә мондый индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзүне планлаштыру турында белдерү кәгазе элек җибәрелмәгән (шул исәптән РФ Шәһр төзелеше кодексының 51.1 статьясының 6 өлеше нигезендә гариза бирүчегә кире кайтарылган). Күрсәтелгән белдерү кәгазе кергән көннән башлап өч эш көне эчендә, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге белдерү кәгазе һәм аңа теркәлгән документлар гариза бирүчегә кире кайтарыла.<br>Бу очракта, төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе җибәрелмәгән дип санала. | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясының 17 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән төзелешенең, реконструкцияләүнең чик параметрларына яки РФ Шәһәр төзелеш кодексы, башка федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килми;<br>2) индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы күренеше планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазенә кушымта булып торучы мондый объектның яки йортның тышкы күренеше тасвирламасына яки планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән типовой архитектура чишелешенә туры килми яки РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 статьясындагы 10 өлешнең 4 пунктында күрсәтелгән нигез буенча, гариза бирүчегә планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килмәү һәм (яки) җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителмәү турында белдерү кәгазе җибәрелгән (алга таба – планлаштырылган төзелеш параметрланың туры килмәве турында белдерү кәгазе) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын федераль яки региональ әһәмиякә ия тарихи җирлек чикләрендә төзегән яки реконструкцияләгән очракта; | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясының 20 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының рөхсәт ителгән файдалану төре планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының рөхсәт ителгән файдалану төренә туры килми;<br>4) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе керү датасына Россия Федерациясенең җир һәм башка законнарына туры китереп билгеләнгән чикләүләр нигезендә, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителми, күрсәтелгән чикләүләр, төзү һәм реконструкцияләү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектына карата территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында кабул ителгән карарда күздә тотылган һәм мондый капиталь төзелеш объекты файдалануга тапшырылмаган очраклардан тыш. | |
| 2.10. Федераль законнарда, алар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу - 15 минуттан да артык түгел. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы | Төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе алынган вакыттан башлап бер көн эчендә | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, шул исәптән федераль законнар һәм Татарстан Республикасының инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә, күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә таләпләр | 1) Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-ноктал Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү; | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 12 пункты;<br>181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | - закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>1) Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>2) кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>3) мәгълүмат стендларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) инвалидларга муниципаль хезмәттән башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>1) документлар кабул иткәндә һәм документлар биргәндә чиратлар;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларның эш итүләренә (эш итмәвенә) шикаятьләр;<br>4) муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларның тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр. | |
| 2.15. Башка таләпләр, шул исәптән КФҮдә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы башка таләпләр | 1) Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи зат белән гариза бирүченең бер тапкыр хезмәттәшлек итүе күздә тотыла. Үзара хезмәттәшлек дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт КФҮдә, КФҮнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ хезмәткәре гамәлгә ашыра.<br>2) Закон нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны электрон формада бирү каралган очракта, мондый запрос Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша бирелә. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненннән соң килә торган эш көнендә теркәлә.<br>Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүгә күчү муниципаль хокукый актлар белән расланган план-график нигезендә гамәлгә ашырылачак. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлешнең 1 пункты |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны КФҮдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга һәм оешмаларга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм гариза бирүчегә бирү;

5) КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче консультация алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша АШТhТҮИгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

АШТhТҮИ белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырыла торган документларның (аларның күчермәләренең) составы, формасы, эчтәлеге буенча һәм кирәк булганда, төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның (аларның күчермәләренең) составы, формасы, эчтәлеге буенча консультация.

3.2.2. Муниципаль хезмәтне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне ТР муниципаль берәмлекләре порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша (https://msu.tatarstan.ru) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша алырга мөмкин.

3.3. Төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән зат эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә шәхсән яки КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен бирә һәм регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра. КФҮнең ерактагы эш урыннарының исемлеге регламентка 5 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гариза бирүченең яки гариза бирүче вәкиленең шәхесен ачыклауны;

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы белән эш иткән очракта);

3) регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерүне;

4) тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүне (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып язулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасыннан файдаланып, төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен кабул итүне һәм теркәүне;

2) керә торган документларны теркәү карточкасын төзүне;

3) документларны кабул итү датасы турында штамп куеп, төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе күчермәсен (булганда) гариза бирүчегә тапшыруны;

4) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен һәм теркәлгән документларны карап тикшерү өчен бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Регламентның 2.8 пункты нигезендә, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гариза бирүчегә төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен һәм документларны аңа кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

1) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

2) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен теркәү – төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе һәм документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен һәм документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе һәм документлар.

3.3.4 Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен, документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрелгән төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе һәм документлар.

3.3.5. АШТһТҮИ башлыгы төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен, документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен АШТһТҮИ шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге башлыгына (алга таба – АШТһТҮИ бүлеге башлыгы) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: АШТһТҮИ бүлеге башлыгына җибәрелгән төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе һәм документлар.

3.3.6. АШТһТҮИ бүлеге башлыгы төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазен, документларны карап тикшерә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрелгән төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе һәм документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.4.1. АШТһТҮИ бүлеге белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында электрон формада запрослар җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон рәвештә җибәрелгән ведомствоара запрослар.

3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган мәгълүматларны бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазьләрен (алга таба – мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Җавап әзерләү һәм җибәрү срогы федераль законнар белән билгеләнә.

Процедураның нәтиҗәсе: АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрелгән мәгълүматлар яки мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм гариза бирүчегә бирү

3.5.1. АШТһТҮИ бүлеге белгече алынган мәгълүматлар нигезендә:

1) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән төзелгән яки рекострукцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары, планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү кәгазе кергән датага, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән төзелешенең, реконструкцияләүнең чик параметрларына һәм капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата законнарның мәҗбүри таләпләренә туры килүне тикшерә (шул исәптән, күрсәтелгән чик параметрлар яки капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләр, планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе тиешле органга кергән көннән соң үзгәртелгән һәм төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе кергән датага гамәлдә булган чик параметрларга һәм капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килүне раслаган очракта). Белдерү кәгазе, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе кергән датага гамәлдә булган чик параметрларга һәм капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килүне раслаган очракта, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе кергән датага гамәлдә булган күрсәтелгән чик параметрларга һәм капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килүне тикшерү гамәлгә ашырыла.

2) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын карау юлы белән, индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы күренеше планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазенә кушымта булып торучы мондый объектның яки йортның тышкы күренеше тасвирламасына (гариза бирүчегә планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килмәү һәм (яки) җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителмәү турында белдерү кәгазе җибәрелмәү шарты белән) яки планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән типовой архитектура чишелешенә туры килүне тикшерә, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын федераль яки региональ әһәмиякә ия тарихи җирлек чикләрендә төзегән яисә реконструкцияләгән очракта;

3) индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының рөхсәт ителгән файдалану төре планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән рөхсәт ителгән файдалану төренә туры килүне тикшерә;

4) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе керү датасына Россия Федерациясенең җир һәм башка законнарына туры китереп билгеләнгән чикләүләр нигезендә, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителүне тикшерә, күрсәтелгән чикләүләр, төзү һәм реконструкцияләү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектына карата территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында кабул ителгән карарда күздә

тотылган һәм мондый капиталь төзелеш объекты файдалануга тапшырылмаган очраклардан тыш;

5) төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазе проектын (алга таба – туры килү турында белдерү кәгазе проекты) әзерли;

6) регламентның 2.9 пункты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, мондый белдерү кәгазен җибәрү өчен барлык нигезләрне күрсәтеп, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килмәве турында белдерү кәгазе проектын (алга таба – туры килмәү турында белдерү кәгазе проекты) әзерли;

7) туры килү турында белдерү кәгазе проектын яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын килештерү өчен АШТһТҮИ бүлеге башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазе теркәлгән көннән башлап җиде эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен АШТһТҮИ бүлеге башлыгына җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе проекты яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.2 АШТһТҮИ бүлеге башлыгы туры килү турында белдерү кәгазе проектын яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны килештерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе проекты яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.3. АШТһТҮИ башлыгы туры килү турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе проекты яисә имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән туры килмәү турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.4 Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары туры килү турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, имзалый һәм аны теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе проекты яисә АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрелгән туры килмәү турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.5. Башкарма комитет Җитәкчесе туры килү турында белдерү кәгазе проектын имзалый һәм аны теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.6. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

1) туры килү турында белдерү кәгазе проектын терки, Башкарма комитет мөһере белән таныклый;

2) туры килү турында белдерү кәгазе проектын АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.7. АШТһТҮИ белгече:

1) туры килү турында белдерү кәгазен яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын теркәү журналында терки;

2) төзелеш тәмамлану турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүчегә (аның вәкиленә) бирә яисә почта аша җибәрә;

4) туры килмәү турында белдерү кәгазе күчермәсен хокукларны теркәү органына, шулай ук түбәндәгеләргә җибәрә:

- күрсәтелгән белдерү кәгазе Регламентның 2.9 пунктының 1 яки 2 пунктында каралган нигез буенча гариза бирүчегә җибәрелгән очракта, дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органына;

- күрсәтелгән белдерү кәгазе Регламентның 2.9 пунктының 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча җибәрелгән очракта, дәүләт җир күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына.

Әлеге пунктның 1, 2, 4 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктның 3 пунктчасында билгеләнә торган процедура әлеге пунктның 2 пунктчасында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән яисә почта аша җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе, хокукларны теркәү органына, башкарма хакимият органнарына җибәрелгән туры килмәү турында белдерү кәгазе күчермәсе.

3.6. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү

3.6.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә, КФҮнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар регламентның 3.3-3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә яисә КФҮгә, КФҮнең ерактагы эш урынына түбәндәгеләрне тапшыра:

1) техник хатаны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

2) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

3) техник хаталар булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза, гариза бирүче (аның вәкиле)

тарафыннан, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып), яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша бирелә.

3.7.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече теркәлгән документлары белән бергә техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне гамәлгә ашыра, гаризаны терки һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм аңа теркәлгән документлар.

3.7.3. Техник хатаны төзәтү турында гариза кергәндә, муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып исәпләнгән документка төзәтмәләр кертү максатында, әлеге регламентның 3.3.3, 3.3.5 һәм 3.5 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла. АШТһТҮИ белгече төзәтелгән документны шәхсән гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә, төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, техник хата булган документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки техник хаталы документның төп нөсхәсен АШТһТҮИгә тапшырганда документны алу мөмкинлеге турындагы хатны гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза кергәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Регламент үтәлешенең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ процедуралары үтәлешен тикшерүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып баруны билгеләнгән тәртиптә үткәрелгән тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедуралары үтәлешен контроль тикшерүләрне билгеләнгән тәртиптә үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәдә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр кылуга контрольне гамәлгә ашыру максатында, Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында рәсми язулар тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында каралмау өчен җаваплы.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары һәм АШТһТҮИ башлыгы регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.5 Регламент үтәлешен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы аша, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле

документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» челтәреннән, шул исәптән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның (Башкарма комитет), Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, КФҮ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану

максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын
төзү яки реконструкцияләү тәмамлану турында
белдерү кәгазе

«___» ____________ 20___ел

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

(төзелеш өчен рөхсәт бирүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы исеме)

1. Төзүче турында мәгълүмат

| | | |
|---|---|---|
| 1.1 | Физик зат төзүче булып торган очракта, физик зат турында мәгълүмат: | |
| 1.1.1 | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | |
| 1.1.2 | Яшәү урыны | |
| 1.1.3 | Шәхесне раслаучы документ реквизитлары | |
| 1.2 | Төзүче булып юридик зат торган очракта, юридик зат турында мәгълүмат: | |
| 1.2.1 | Исеме | |
| 1.1.2. | Урнашу урыны | |
| 1.2.3 | Юридик затның бердәм дәүләт юридик затлар реестрында дәүләт теркәве турында дәүләт теркәү номеры, чит ил юридик заты гариза бирүче булып торган очрактан тыш | |
| 1.2.4 | Салым түләүченең идентификация номеры, гариза бирүче булып чит ил юридик заты торган очрактан тыш | |

## 2. Җир участогы турында мәгълүматлар

| | | |
|---|---|---|
| 2.1 | Җир участогының кадастр номеры (булган очракта) | |
| 2.2 | Җир участогының адресы яки урнашу урынының тасвирламасы | |
| 2.3 | Төзүченең җир участогына хокукы турында мәгълүматлар (хокук билгеләүче документлар) | |
| 2.4 | Җир участогына башка затларның хокуклары булу турында мәгълүматлар (булган очракта) | |
| 2.5 | Җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану төре турында мәгълүматлар | |

## 3. Капиталь төзелеш объекты турында мәгълүматлар

| | | |
|---|---|---|
| 3.1 | Капиталь төзелеш объектыннан (индивидуаль торак төзелеше объектыннан яки бакча йортыннан) рөхсәт ителгән файдалану төре турында мәгълүматлар | |
| 3.2 | Белдерү кәгазен бирү максаты (төзү яки реконструкцияләү) | |
| 3.3 | Параметрлар турында мәгълүматлар: | |
| 3.3.1 | Җир өстендәге этажлар саны | |
| 3.3.2 | Биеклеге | |
| 3.3.3 | Җир участогы чикләреннән читкә чыгу турында мәгълүматлар | |
| 3.3.4 | Төзелеш мәйданы | |

4. Җир участогында төзелгән яки реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының схематик сурәте

Элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы:

___

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында яисә төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәве турында белдерү кәгазен түбәндәге ысул белән җибәрүегезне сорыйм:

___

___

(почта адресына һәм (яки) электрон почта адресына җибәрү юлы белән яки төзелеш өчен рөхсәт бирүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы яки җирле үзидарә органында кулга тапшырып, шул исәптән күпфункцияле үзәк аша)

Әлеге белдерү кәгазе белән ___

(шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты)

мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүлү өчен билгеләнмәвен, шулай ук хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру өчен дәүләт пошлинасы түләүне раслыйм

___.

(түләү документының реквизитлары)

Әлеге белдерү кәгазе белән мин,

___

___,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм (төзүче булып физик зат торган очракта).

| ___ | ___ | ___ |
|---|---|---|
| (төзүче булып юридик зат торган очракта, вазыйфа) | (имза) | (имза расшифровкасы) |

М.У.

(булган очракта)

Әлеге белдерү кәгазенә теркәлә:

___

___

(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясының 16 өлешендә каралган документлар (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, ст. 16; 2006, № 31, ст. 3442; № 52, ст. 5498; 2008, № 20, ст. 2251; № 30, ст. 3616; 2009, № 48, ст. 5711; 2010, № 31, ст. 4195; 2011, № 13, ст. 1688; № 27, ст. 3880; № 30, ст. 4591; № 49, ст. 7015; 2012, № 26, ст. 3446; 2014, № 43, ст. 5799; 2015, № 29, ст. 4342, 4378; 2016, № 1, ст. 79; 2016, № 26, ст. 3867; 2016, № 27, ст. 4294, 4303, 4305, 4306; 2016, № 52, ст. 7494; 2018, № 32, ст. 5133, 5134, 5135)

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

______________________________________________________________________________
төзелеш өчен рөхсәт бирүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы исеме

Кемгә: ______________________________

______________________________

______________________________

Почта адресы: ______________________

______________________________

______________________________

Электрон почта адресы
(булган очракта): ___________________

______________________________

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында белдерү кәгазе

«_____» _____________ 20____ ел                                        № ________

_______________________________________ җибәрелгән
(белдерү кәгазен җибәрү датасы)
________________________________________ теркәлгән
(белдерү кәгазен теркәү датасы һәм номеры)

индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү тәмамлану турында белдерү кәгазен (алга таба – белдерү кәгазе) карап тикшерү нәтиҗәләре буенча,

______________________________________________________________________________

белдерү кәгазендә күрсәтелгән һәм ______________________________________________

______________________________________________________________________________
(җир участогының кадастр номеры (булган очракта), җир участогының адресы яки урнашу урынының тасвирламасы)

______________________________________________________________________________

җир участогында урнашкан ___________________________________________________
(төзелгән яки реконструкцияләнгән)

______________________________________________________________________________
(индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының)
шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында хәбәр итә.

_________________________________________ ____________ ______________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

М.У.

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

______________________________________________________________
төзелеш өчен рөхсәт бирүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы исеме

Кемгә: ____________________________
____________________________________
____________________________________

Почта адресы: ______________________
____________________________________
____________________________________

Электрон почта адресы
(булган очракта): ___________________
____________________________________

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәве турында белдерү кәгазе

«_____» _____________ 20____ ел № ________

______________________________________ жибәрелгән
(белдерү кәгазен җибәрү датасы)
______________________________________ теркәлгән
(белдерү кәгазен теркәү датасы һәм номеры)

индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү тәмамлану турында белдерү кәгазен (алга таба – белдерү кәгазе) карап тикшерү нәтиҗәләре буенча,

______________________________________________________________
белдерү кәгазендә күрсәтелгән һәм ________________________________
______________________________________________________________
(җир участогының кадастр номеры (булган очракта), җир участогының адресы яки урнашу урынының тасвирламасы)
______________________________________________________________
җир участогында урнашкан ______________________________________
(төзелгән яки реконструкцияләнгән)
______________________________________________________________
(индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының)
түбәндәге нигезләр буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәве турында хәбәр итә:

1. ________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 19 өлешнең 1 пунктында күрсәтелгән (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 16 ст.; № 32, 5135) һәм җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларына яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, башка федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килмәү турында мәгълүматлар)

2. ________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы күренеше төзү яки реконструкцияләү планлаштырыла торган индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты турында белдерү кәгазенә (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кәгазе) яки планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән типовой архитектура чишелешенә кушымта булып торучы мондый объектның яки йортның тышкы күренеше тасвирламасына туры килмәү турында мәгълүматлар, яки төзүчегә планлаштырыла торган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килмәү һәм яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 статьясындагы 10 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 16; 2018, № 32, ст. 5133, 5135) нигез буенча җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителмәү турында белдерү кәгазе җибәрелгән булу хакында мәгълүматлар, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын федераль яки региональ әһәмияткә ия тарихи җирлек чикләрендә төзегән яисә реконструкцияләгән очракта)

3. ________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(төзелгән яки реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының рөхсәт ителгән файдалану төре планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектыннан яки бакча йортыннан рөхсәт ителгән файдалану төренә туры килмәү турында мәгълүматлар)

4. ________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(белдерү кәгазе керү датасына Россия Федерациясенең җир һәм башка законнарына туры китереп билгеләнгән чикләүләр нигезендә, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителмәү турында мәгълүматлар, күрсәтелгән чикләүләр, төзү һәм реконструкцияләү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектына карата территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында кабул ителгән карарда күздә тотылган һәм мондый капиталь төзелеш объекты файдалануга тапшырылмаган очраклардан тыш)

________________________________________ ______________ ________________________

(имза) (имзаның расшифровкасы)

М.У.

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә
___________________________________

__________________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
________________________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)

Язылган: ______________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ___________________________________________________
________________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:
________________________________________________________________________________.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

_____________ ________________ (________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

КФҮнең ерактагы эш урыннарының
исемлеге

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр
күрсәтү буенча КФҮ» ДБУ филиалы

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча КФҮ» МБУ, адресы: Кол Гали бульвары, 25 Е йорт (Яңа шәһәр 59/04).

2. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча КФҮ» ДБУ Яр Чаллы филиалының өстәмә офисы: Тынычлык проспекты, 62 йорт (Яңа шәһәр 3/16).

Төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
кушымта (белешмә)

Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының
телефоннары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | 30-55-08 | gradoctroitel@mail.ru |
| Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы | 30-55-08 | gradoctroitel@mail.ru |
| Шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге | 30-58-12 | gradoctroitel@mail.ru |
| Бүлек белгече | 30-58-12 | gradoctroitel@mail.ru |